ГЛАВА
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**09.07.2025**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 01-195**

Зеленодольск муниципаль районы Башлыгының 2025 елның 20 июнендәге 01-175 номерлы карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районы Советына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Зеленодольск муниципаль районы Советында «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы таләпләрен гамәлгә ашыру максатларында

**КАРАР БИРӘМ**:

1. Зеленодольск муниципаль районы Башлыгының 2025 елның 20 июнендәге 01-175 номерлы карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районы Советына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибенә үзгәрешләр кертергә:

5.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.2. Язма мөрәҗәгатьтә мөрәҗәгать җибәргән гражданның фамилиясе яисә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы күрсәтелмәгән очракта, мөрәҗәгатькә җавап бирелми. Әгәр күрсәтелгән мөрәҗәгатьтә әзерләнә торган, башкарыла торган яисә кылынган хокукка каршы гамәл турында белешмәләр булса,, мөрәҗәгать тиешле компетенциясе булган дәүләт органына җибәрелергә тиеш.».

2. Әлеге Карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында, шулай ук Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми (http://pravo.tatarstan.ru) порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Советы аппараты Җитәкчесе И.М. Хантимеровка йөкләргә.

**М.П. Афанасьев**